ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.08.2022 г. Заинск № 389

**«Зәй муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Зәй муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарынакого муниципального района» (17.12.2018 ел №1864, 22.03.2019 ел №151, 05.11.2019 ел № 574, 17.12.2019 ел №646, 20.12.2019 ел №648, 10.06.2020 ел №247, 10.07.2020 ел №298, 14.10.2021 ел № 617, 12.11.2021 ел № 680, 27.01.2022 ел № 44 карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күрсәтелгән карар белән расланган Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VI бүлекнең 14.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.3. Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру һәм ирешелгән күрсәткечләрне саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче

хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, средстволар булганда, бер тапкыр акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр гомуми белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып билгеләнә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасарларына, баш бухгалтерына, локаль норматив актларда билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәр өчен квартал саен башкарыла ала. Кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасарларына, баш хисапчыга гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләренең 70 проценты күләмендә билгеләнә.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Гомуми белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Гомуми белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына гомуми белем бирү оешмасының нормативларга, күрсәтелә торган хезмәтләр санына туры китереп билгеләнә торган акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Әлеге нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләү гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә агымдагы финанс елына гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәрен дә кертеп).

3. Гомуми белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү, финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (ай, квартал, ел) әлеге нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондында экономия булганда кызыксындыру түләүләре хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә түләнә (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәрен дә кертеп).

Гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәренә тиешле чорда хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә башкарылган кызыксындыру түләүләре күләме, бу чорда хезмәт нормасын (хезмәт бурычларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик хезмәткәрләр, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән тыш).

Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве гомуми белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс тәэминатының барлык чыганаклары исәбенә, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фонды экономиясеннән файдаланган өчен җаваплылык гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

1.2. Күрсәтелгән карар белән расланган Зәй муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

V бүлекнең 13.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.3. Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатында педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, средстволар булганда, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү карала. Күрсәтелгән максатларда акчаларны түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме мәктәпкәчә белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәр өчен түләнергә мөмкин.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, эшчәнлекләренең локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелек критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне башкарган өчен саен башкарылырга мөмкин. Кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик күләме җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләренең 70 проценты күләмендә билгеләнә.»;

VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"VIII. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру күрсәтелгән хезмәтләрнең нормативлары, саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына мәктәпкәчә белем бирү оешмасының средстволары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Әлеге нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләү мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәрен дә кертеп) агымдагы финанс елына хезмәт өчен мәктәпкәчә белем бирү мәгариф оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган средстволар исәбеннән башкарыла.

3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү, финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (ай, квартал, ел) әлеге нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасының локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондында экономия булганда кызыксындыру түләүләре хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә түләнә (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәрен дә кертеп).

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәренә тиешле чорда хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә башкарылган кызыксындыру түләүләре күләме, бу чорда хезмәт нормасын (хезмәт бурычларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик

хезмәткәрләр, мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән тыш).

Хезмәт өчен түләү фонды экономиясе исәбенә кызыксындыру түләүләре күләме мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә мәктәпкәчә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс тәэминатының барлык чыганаклары исәбенә, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фонды экономиясеннән файдаланган өчен җаваплылык мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

1.3. Күрсәтелгән карар белән расланган Зәй муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VI бүлекнең 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген күтәрү һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, Россия Федерациясе Президентының «2012-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең милли стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы Указы белән билгеләнгән, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча, чаралар булганда, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатлар өчен түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме өстәмә белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасарларына, баш хисапчысына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, локаль норматив актларда билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүләр мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен ай саен, квартал саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча башкарылырга мөмкин. Өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләренең 70 проценты күләмендә билгеләнә.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру финанс чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәтләр саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына өстәмә белем бирү оешмасы чаралары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм өстәмә белем бирү оешмаларында финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Әлеге нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләү өстәмә белем бирү мәгариф оешмасы хезмәткәрләренә агымдагы финанс елына хезмәт өчен өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган средстводлар исәбеннән башкарыла (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәрен дә кертеп).

3. Өстәмә белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү, финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (ай, квартал, ел) әлеге нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән өстәмә белем бирү оешмасының локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондында экономия булганда кызыксындыру түләүләре хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә түләнә (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәрен дә кертеп).

Өстәмә белем бирү оешмасы хезмәткәренә тиешле чорда хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә башкарылган кызыксындыру түләүләре күләме, бу чорда хезмәт нормасын (хезмәт бурычларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик хезмәткәрләр, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән тыш).

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабына өстәмә белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру түләве күләме өстәмә белем бирү мәгариф оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс тәэминатының барлык чыганаклары исәбенә, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фонды экономиясеннән файдаланган өчен җаваплылык өстәмә белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

1.3. Күрсәтелгән карар белән расланган Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерләүче муниципаль физкультура спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Спорт резервын әзерләү оешмаларының хезмәткә түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Спорт резервы әзерләү оешмасының хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына спорт резервы әзерләү оешмасының финанс чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәтләр саны нигезендә билгеләнгән акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм спорт резервы әзерләү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Әлеге нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләү спорт резервы әзерләү оешмасы хезмәткәрләренә агымдагы финанс елына спорт резервы әзерләү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәрен дә кертеп).

3. Спорт резервы әзерләү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү, финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (ай, квартал, ел) әлеге нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән спорт резервы әзерләү оешмасының локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондында экономия булганда, кызыксындыру түләүләре хезмәт өчен түләү фонды экономиясен барлыкка китергән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә башкарыла (эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәрен дә кертеп).

Спорт резервы әзерләү оешмасы хезмәткәренә тиешле чорда хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә башкарылган кызыксындыру түләүләре күләме, бу чорда хезмәт нормасын (хезмәт бурычларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләрдән һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләрдән, спорт резервы әзерләү оешмасы җитәкчесеннән тыш).

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабына спорт резервы әзерләү оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру түләве күләме спорт резервы әзерләү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс тәэминатының барлык чыганаклары исәбенә, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фонды экономиясеннән файдаланган өчен җаваплылык спорт резервы әзерләү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Сәфәргалиев Э.Р.
3-27-42

Имаметдинова Е.М.
2-80-44